**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_____________ № ________

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 21 декабрендәге ПР-325 номерлы «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүдә кичектергесез ихтыяҗ барлыкка килгәндә җирле бюджет акчалары исәбеннән кире кайтарыла торган һәм (яисә) кире кайтарылмый торган нигездә өстәмә ярдәм күрсәтү очракларының тәртибен һәм исемлеген раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 21 декабрендәге ПР-325 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүдә кичектергесез ихтыяҗ барлыкка килгәндә җирле бюджет акчалары исәбеннән кире кайтарыла торган һәм (яисә) кире кайтарылмый торган нигездә өстәмә ярдәм күрсәтү очракларының тәртибен һәм исемлеген раслау турында», Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүдә кичектергесез ихтыяҗ туганда җирле бюджет акчалары исәбеннән өстәмә ярдәм күрсәтү очраклары тәртибенә һәм исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

"- товарлар җитештерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү турындагы шартнамәләр буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр буенча субсидияләр алучыларның һәм тәэмин итүчеләр булып торучы затларның (гавами-хокукый берәмлекләр катнашындагы дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән тыш), шулай ук мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында аларның устав капиталларында коммерция оешмалары), субсидияләр бирүче бюджет акчаларын баш бүлүче һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 3 пунктының 5 пунктчасында каралган тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы.»;

1.2. 4.6 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4.6. Субсидияләр бирүче бюджет акчаларын баш бүлүче субсидияләр алучыларга һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән затларга карата бюджет акчаларын, аларның субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268_1 һәм 269_2 статьялары нигезендә дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүләр гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.Р.Сираева